ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тынычлык урамы, 100а йорт,
Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 03 » февраль 2023 ел №7

«Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитетының 23.12.2022 № 24 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 04.08.2022 № 55 карары нигезендә, 15.11. 2022 №1, 16.11. 2022 №2, 17.11. 2022 №3, 17.11 2022 №4 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымы чараларын җыю тәртибе турында» Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитетының 23.12.2022 № 24 карары белән расланган Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 һәм 4 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм түбәндәге адреслар буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Яңа Кишет авылы, Дуслык ур., 100а йорты; ТР, Арча районы, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин ур., 26а йорты, ТР, Арча районы, Кышкар авылы, Яңа урамы, 125 йорт, ТР, Арча районы, Симетбаш авылы, Үзәк урамы, 19а йорты.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Ф.И.Ахмадуллин